Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Лельвиж авыл җирлеге Советы

КАРАР

24 март, 2026 ел № 7

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2025 елның 30 октябрендәге 2 номерлы Лельвиж торак пунктындагы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Лельвиж торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Лельвиж авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елның 7 апрелендә 9 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Лельвиж авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 30 октябрендәге 2 номерлы Кукмара муниципаль районы Лельвиж торак пунктындагы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. 2026 елның 7 апрелендә 14 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Лельвиж авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 30 октябрендәге 2 номерлы Кукмара муниципаль районы Лельвиж торак пунктындагы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2025 елның 30 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы: Э.Ю. Игнатьева